ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның «10» октябреннән № 252

Халыкка күрсәтелә торган түләүле хезмәтләргә чик бәяне раслау турында

Халыкка түләүле хезмәт күрсәтү хокукына ия муниципаль учреждениеләрнең үтенечнамәләрен карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2024-2025 уку елына Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә халыкка түләүле хезмәтләр күрсәтү хокукы булган муниципаль учреждениеләр тарафыннан халыкка күрсәтелә торган түләүле хезмәтләргә чик бәяне кушымтага нигезләнеп расларга

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесенә әлеге карарны «Яңа Чишмә хәбәрләре» газетасында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: http:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Халыкка күрсәтелә торган түләүле хезмәтләргә чик бәяне раслау

турында» 2023 елның 01 сентябрендәге 191 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның «10» октябреннән
252 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендәзакон нигезендә халыкка түләүле хезмәтләр күрсәтү хокукына ия булган муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр тарафыннан халыкка күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр өчен чик бәя

| № т/б | Хезмәтнең атамасы | Үлчәү берәмлеге | Бәясе, сумнарда |
|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре | | | |
| 1 | Нәфис-эстетик цикл | 30 минут | 300,00 |
| 2 | Физкультура-сәламәтләндерү юнәлеше | 30 минут | 300,00 |
| 3 | Сәламәтләндерү һәм медицина хезмәтләре | 30 минут | 300,00 |
| 4 | Психолог белән дәресләр | 30 минут | 300,00 |
| 5 | Логопед белән дәресләр | 30 минут | 300,00 |
| 6 | Ял көне төркеме | 6 сәгать | 350,00 |
| 7 | Гомуми интеллектуаль юнәлеш | 30 минут | 300,00 |